# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстын раслау өлешендә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2002, № 12 (II өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**18 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимны – әлеге Законда каралган очракларда башкарыла торган музыкаль-поэтик әсәр.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимнының музыкаль редакциясен һәм текстын әлеге Законның 3 нче һәм 4 нче кушымталары нигезендә расларга.»;

2) 24 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**24 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимны оркестр, хор, оркестр-хор йә башка вокаль яисә инструменталь вариантта башкарылырга мөмкин. Бу чакта тавыш язу чаралары кулланылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны расланган музыкаль редакциясенә һәм текстына төгәл туры китереп башкарылырга тиеш.»;

3) түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасының
дәүләт символлары турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны
тексты
(Рамазан Байтимеров сүзләре,
рус теленә Филипп Пираев тәрҗемәсе)

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живет в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 18 марты
№ 23-ТРЗ